КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 4 март г.Казань № 119

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Аерым юнәлешләр буенча агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме чаралары турында» 2021 ел, 30 июнь, 514 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Аерым юнәлешләр буенча агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме чаралары турында» 2021 ел, 30 июнь, 514 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 5 август, 680 нче; 2021 ел, 31 август, 788 нче; 2021 ел, 7 сентябрь, 835 нче; 2021 ел, 25 ноябрь, 1127 нче; 2021 ел, 22 декабрь, 1266 нчы; 2022 ел, 15 март, 240 нчы; 2022 ел, 22 июль, 707 нче; 2022 ел, 16 сентябрь, 1009 нчы; 2022 ел, 13 декабрь, 1319 нчы; 2022 ел, 21 декабрь, 1389 нчы; 2023 ел, 21 февраль, 168 нче; 2023 ел, 4 июль, 786 нчы; 2023 ел, 9 август, 961 нче; 2023 ел, 5 октябрь, 1239 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта:

өченче, алтынчы, җиденче, сигезенче, тугызынчы абзацлар үз көчен югалткан дип танырга;

унөченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Бөртекле, кузаклы ашлык, майлы (рапс һәм соядан тыш), азык авыл хуҗалыгы культураларын җитештерүгә ярдәм күрсәтү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджеттан финанслаша торган субсидия бирү тәртибен;»;

унбишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Сөт җитештерүгә ярдәм күрсәтү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджеттан финанслаша торган субсидия бирү тәртибен;»;

унҗиденче абзацта «авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә» сүзләрен төшереп калдырырга;

егерменче, егерме икенче һәм егерме дүртенче абзацлар үз көчләрен югалткан дип танырга;

әлеге карар белән расланган Үсемлекчелек, техник киндер һәм (яки) озын сүсле җитен җитештерүне үстерү өлкәсендә файдалану юнәлешләре мөстәкыйль билгеләнә торган ярдәм күрсәтү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджеттан финанслаша торган субсидия бирү тәртибен, Сөт терлекчелегендә продуктивлыкны арттыруга юнәлдерелгән чыгымнарның бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджеттан финанслаша торган субсидия бирү тәртибен, Нәселле терлекчелеккә ярдәм күрсәтү өчен авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджеттан финанслаша торган субсидия бирү тәртибен яңа редакциядә (карарга теркәләләр) бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин